ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**

29 гыйнвар 2018ел

**КАРАР**

№ 326

Гражданнарны аз керемле дип тану максатында аларның керем күләменең һәм мөлкәт бәясенең чик кыйммәтен раслау турында

Гражданнарны аз керемле дип тану һәм аларга муниципаль торак фондындагы торак биналарны социаль наем килешүе буенча бирү максатында, Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт торак фондыннан һәм муниципаль торак фондыннан социаль наем килешүләре буенча гражданнарның аларга торак урыннары бирү хокукларын гамәлгә ашыру турында» 2007 елның 13 июлендәге 31-ТРЗ санлы Законы һәм шәһәр Уставының 41 маддәсе нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. 2018 елга гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче керем күләменең һәм гаилә әгъзалары яки ялгыз яшәүче граждан милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең түбәндәге чик кыйммәтләрен билгеләргә:

1) гаиләнең һәр әгъзасына яки ялгыз яшәүче гражданга туры килүче кеpемнең чик кыйммәте – 7 378 сум;

2) гаилә әгъзаларының яки ялгыз яшәүче гражданның милкендәге һәм салым салынырга тиешле мөлкәт бәясенең чик кыйммәте:

- ялгыз яшәүче граждан өчен – 672 804 сум;
- ике кешелек гаилә өчен – 1 345 608 сум;
- өч кешелек гаилә өчен – 2 018 412 сум;
- дүрт кешелек гаилә өчен – 2 691 216 сум;
- биш кешелек гаилә өчен – 3 364 020 сум;
- алты кешелек гаилә өчен – 4 036 824 сум;
- җиде кешелек гаилә өчен – 4 709 628 сум;
- сигез кешелек гаилә өчен – 5 382 432 сум.

2. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитет
Җитәкчесе

Р.Ә. Абдуллин